Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының “Тирсә авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Чишмә торак пунктында гражданнар җыенының нәтиҗәләре турында карар

**22.11.2024 ел** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 22 ноябрендә 15 сәгать 00 минутта узган гражданнарның этаплап җыеннары нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы “Тирсә авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Чишмә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган кешедән, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнар, 1 төркем инвалидлардан, студентлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче затлардан һәм ирегеннән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгән, ирекле рәвештә киткәннәрдән) һәм аларның гаилә әгъзаларын (аларның ата-аналарын, хатыннары, балигъ булмаган балаларын) түләүдән азат итеп һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне үтәү буенча алынган мәсьәләләрне хәл итүгә юллап, түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдереп, гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга: 2025 елда үзара салым акчасын 1000 сум күләмендә кертү һәм куллану белән килешәсезме?:

1 Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Чишмә авылы юлларны өчен вак таш сатып алу, аларны җәю һәм автомобиль юлларын карап тоту буенча башка чыгымнар).

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 25 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 14 кеше, бу 56 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында 14 катнашучы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының “Тирсә авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Чишмә торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының “Тирсә авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Чишмә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, студентлардан, укытуның көндезге формасында белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнар, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм иректән мәхрүм итү урыннарында булучы затлардан тыш, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (мобилизацияләнгән, ирекеләр контракты буенча хәрби хезмәткәрләр) һәм аларның гаилә әгъзаларын (ата-аналарын, ирләрен хатыннарын, балигъ булган балаларны) түләүдән азат итеп, 2025 елда үзара салым чараларын 1200 сум күләмендә кертергә.

3. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Чишмә авылы юлларны өчен вак таш сатып алу, аларны җәю һәм автомобиль юлларын карап тоту буенча башка чыгымнар).

4. Әлеге карарны мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Муниципаль берәмлек башлыгы

Совет Терсинского сельского поселения Тирсә авыл җирлеге Советы

Р.А. Низамбиев